РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22 ноябрь, 2024 ел №19а

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 ел, № 14 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2. Салым ставкаларын күләмендә билгеләргә:

2.1. 0,1 процентка карата:

2.1.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән;

2.1.2. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

2.2. 0,2 процентка карата:

2.2.1. фатирлар, фатир өлешләре;

2.2.2. бүлмә;

2.3. 0,3 процентка карата:

2.3.1. торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

2.3.2. төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

2.3.3. составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

2.4. 2 процент:

2.4.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

2.4.2. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

2.4.3. һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

2.4.4. 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда – гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата салым салу объектларына карата 2 процент, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Хадиуллин